КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 17 апрель г.Казань № 240

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт физик культура һәм спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 15 август, 671 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт физик культура һәм спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 15 август, 671 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 15 апрель, 290 нчы, 2021 ел, 26 июль, 645 нче, 2021 ел, 30 октябрь, 1030 нчы, 2022 ел, 20 июнь, 587 нче, 2022 ел, 14 сентябрь, 1002 нче, 2023 ел, 16 октябрь, 1312 нче, 2024 ел, 19 июнь, 442 нче, 2024 ел, 12 сентябрь, 768 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт физик культура һәм спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Дәүләт физик культура һәм спорт оешмалары хезмәткәрләренең база окладларын билгеләү

2.1. Дәүләт физик культура һәм спорт оешмаларында физик культура хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | 1 айга база оклады күләме, сум |
|---|---|---|
| Беренче дәрәҗә физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Спорт залы буенча кизү торучы | 23 320 |
| Икенче дәрәҗә физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Адаптацияли торган физик культура буенча инструктор-методист | 24 185 |
| | Спорт буенча инструктор | |
| | Спортчы-инструктор | |
| | Спорт техникасын эксплуатацияләү һәм ремонтлау буенча техник | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Адаптацияли торган физик культура буенча инструктор-методист | 24 190 |
| | Физкультура-спорт оешмалары инструктор-методисты | |
| | Тренер | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Физкультура-спорт оешмаларының өлкән инструктор-методисты | 24 200 |

2.2. Дәүләт физик культура һәм спорт оешмаларында мәгариф хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | 1 айга база оклады күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Физик культура буенча инструктор | 24 900 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Инструктор-методист | 25 000 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Методист | 25 140 |
| | Өлкән инструктор-методист | |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлек: кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту һәм консультация бирү пункты, укыту (укыту-җитештерү) остаханәсе һәм балаларга өстәмә белем бирә торган мәгариф программалары тормышка ашырылган башка структур бүлекчәләр мөдире (икенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларыннан башка) | 25 300 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Мәгариф программасы һәм балаларга өстәмә белем бирә торган мәгариф программасы тормышка ашырылган, аерымланган структур бүлекчә мөдире (башлыгы) | 25 350 |

2.3. Дәүләт физик культура һәм спорт оешмаларында медицин хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | 1 айга база окладының күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Шәфкать туташы (медицина абыйсы) | 25 240 |
| | Массаж буенча шәфкать туташы (массаж буенча медицина абыйсы) | |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән шәфкать туташы (өлкән медицина абыйсы)* | 26 940 |
| «Табиблар һәм провизорлар» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗә- | 29 170 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | ләренә кертелгән табиб-белгечләрдән башка) | |
| «Учреждениеләрнең югары медицина һәм фармацевтика белемле структур бүлекчәләр җитәкчеләре (табиб-белгеч, провизор)» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлек (бүлек, бүлек, лаборатория, кабинет, отряд) мөдире (стационарларның хирургия профилендәге бүлекләре мөдирләреннән башка) | 32 150 |
| *Вазыйфа оешмада өч һәм аннан да күбрәк шәфкать туташлары (медицина абыйлары) буйсынуда булганда билгеләнә | | |

2.4. Дәүләт физик культура һәм спорт оешмаларында мәдәният хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфа исеме | 1 айга база окладлы күләме, сум |
|---|---|
| «Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Билетлар контролеры | 24 450 |
| «Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Билет кассалары мөдире | 24 950 |

2.5. Дәүләт физик культура һәм спорт оешмаларында авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | 1 айга база окладлы күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| «Өченче дәрәҗә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Ветеринария табибы | 24 950 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | II категорияле ветеринария табибы | 25 000 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | I категорияле ветеринария табибы | 25 060 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Төп ветеринария табибы | 25 150 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| «Дүртенче дәрәҗә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Баш агроном | 26 400»; |

16 нчы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16 нчы таблица

Дәүләт физик культура һәм спорт оешмалары җитәкчеләренең база окладлары күләмнәре

| Җитәкченең хезмәте өчен түләү буенча төркем | Күләм күрсәткеченең зурлыгы (хезмәткәрләрнең штат саны), кеше | База оклады, сум |
|---|---|---|
| 1 | 20 га кадәр | 31 350 |
| 2 | 21 – 40 | 32 450 |
| 3 | 41 – 60 | 33 550 |
| 4 | 61 һәм аннан да күбрәк | 34 100»; |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының физик культура һәм спорт буенча дәүләт оешмалары эшчеләр гомумтармак эшче һөнәрләре, мәдәният, сәнгать һәм кинематография һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәнең II бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Дәүләт физик культура һәм спорт оешмаларында эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладларын билгеләү

2.1. Дәүләт физик культура һәм спорт оешмаларында эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | 1 айга база оклады күләме, сум |
|---|---|
| 1 | 2 |
| «Беренче дәрәҗә эшчеләр гомумтармак һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 23 320 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 23 520 |

| 1 | 2 |
|---|---|
| «Икенче дәрәҗә эшчеләр гомумтармак һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 23 660 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 23 840 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 24 020 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 24 550 |

2.2. Дәүләт физик культура һәм спорт оешмаларында җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | 1 айга база оклады күләме, сум |
|---|---|
| 1 | 2 |
| «Беренче дәрәҗә хезмәткәрләр гомумтармак вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 23 320 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 23 520 |
| «Икенче дәрәҗә хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 23 660 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 23 840 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 24 020 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 24 240 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | 24 430 |
| «Өченче дәрәҗә хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 24 620 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 24 820 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 25 050 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 25 250 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | 25 450 |
| «Дүртенче дәрәҗә хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 26 400 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 26 600 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 26 800 |

2.3. Физик культура һәм спорт дәүләт оешмасы хезмәткәре вазыйфасының һәм һөнәренең эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләре һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифалары буенча һөнәри квалификация төркемнәренең квалификация дәрәҗәләренә туры килүе Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнә.

2.4. Физик культура һәм спорт дәүләт оешмаларында берьюлы ике урында, шулай ук эш вакыты тулы булмаган шартларда эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә йә башкарылган эшләр күләменә карап гамәлгә ашырыла. Төп вазифа буенча, шулай ук төп урыннан тыш башка урында эшләү тәртибендә биләнә торган вазифа буенча хезмәт хакы күләмнәрен билгеләү һәр вазифа буенча аерым билгеләнә.».

2. Әлеге карар 2025 елның 1 маеннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин